**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет**
**Балтачевского сельского**
**поселения» Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Молодежная, д 1а , с. Балтачево
Азнакаевского муниципального района
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**«Балтач авылы жирлеге**
**Советы**

Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы,
Яшьлэр урамы, 1а
423302, Тел. (8-292) 4-47-23


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» ноябрь 2021 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында, Балтач авылында теркәлгән һәм Үзәк урамы буенча 1- 42, 8 Март урамы 1-14 йортлар буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын 2021 елның 20 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында, Балтач авылында теркәлгән һәм 8 Март урамы буенча 14 а -37 нче йортлар буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын 2021 елның 26 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында, Балтач авылында теркәлгән һәм А.Алиш урамы буенча 1 – 25,Яшьлэр урамы 2-11 нче йортлар буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын 2021 елның 26 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында, Балтач авылында теркәлгән һәм Яшьләр урамы буенча 12 - 62 нче йортлар буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын 2021 елның 26 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3.Билгеләү:
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач авыл җирлегендә үзара салым кертү буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитеты.;
- гражданнар Җыенының беренче этабын уздыру вакыты-2021 елның 26 ноябрендә 09.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар Җыенының икенче этабын уздыру вакыты-2021 елның 26 ноябрендә 11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;
-- гражданнар Җыенының икенче этабын уздыру вакыты-2021 елның 26 ноябрендә 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
-- гражданнар Җыенының икенче этабын уздыру вакыты-2021 елның 26 ноябрендә 16.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

4.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
- 2020 елның 20 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга Балтач авылы, Молодежная урамы, 1А йорт адресы буенча бирергә.;
"Татар теле" фәнен өйрәнүгә карата уңай омтылышта булу, татар теле белән даими кызыксыну һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштерү.;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Балтач торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.
5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар,80 яшьтән өлкәнерәк пенсионерлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:
- Урам яктырткычлары, яктырткычлар ,махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру ,Балтач авылында килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Балтач авылы территориясендә чүп үләннәрен чабу;
- Балтач авылы зираты территориясендә чүп уләннәрен чабу
- Балтач авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү,
"Җиңү Көне « Сабантуй», « Өлкәннәр көне»,» Яңа ел"
- Трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу
- Трактор өчен җиһазлар сатып алу ( төягеч, чапкыч)

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә:

http://pravo.tatarstan.ru бүген Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) һәм Балтач авылы,Молодежная ур., 1А йорт,Центральная ур., 37 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Рәис Л.Л.Хәбипов